| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2019 **Кече Мәми авылы** №11

**Кече Мәми авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәме авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кече Мәми авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны, җирле референдум мәсьәләләрен формалаштырып, түбәндәгечә тәкъдим итәргә:

"Сез 2020 елда 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә хокуклы Кече Мәми авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү кертүгә килешәсезме?

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:*

- материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- коены ремонтлау, төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм төзекләндерү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмати стендларда һәм Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http:// mmemin-kaybici.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советына җибәрергә.

4. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Кече Мәми авыл җирлеге**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Татарстан Республикасы** **Е.Н.Алексеева**